**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Казиле  авыл җирлеге Атабай авылында**
**гражданнарга үзара салым кертү турында**

15  нче  ноябрь  2024 ел                                                                   № 3

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында”  2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының  35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Атабай авылында гражданнар җыены **карар итте** :

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Атабай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, олешчэ мобилизациядэ булганнар хэм аларнын гаилэ эгьзаларыннан тыш  һәр балигъ булган кешедән 500сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карау
2) торак пункт территориясен төзекләндерү
3) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.

3. Әлеге карарны Иске Казиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/),   хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле  авыл җирлеге башлыгы:                                    И.Х.Сагьдиев